# КЕРЕШ

Һәрбер халыкның рухи кыйммәтләрен, яшәү рәвешен, күзаллауларын чагылдырган тел берәмлекләре бар. Алар аша тарихны, милли психологияне, башка милләтләр белән бәйләнеш нәтиҗәләрен, гореф-гадәтләрне, хәзерге көнитешне ачык аңларга мөмкин. Әлеге берәмлекләр арасында кеше исемнәре системасы аерым урын били. Исем – беренче чиратта халык турындагы мәгълүматны туплаган мәдәният берәмлеге. Бу төр берәмлекләр, кешелек яшәешенең гомуми якларын гәүдәләндерү белән бергә, һәр халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклауда, милли телнең киләчәген билгеләүдә һәм, ниһаять, җәмгыятьнең иң әһәмиятле берәмлеге саналган гаилә кыйммәтләрен, традицияләрен аныклаганда төп күрсәткеч булып торалар. «Исем – милләтнең көзгесе» дигән мәгълүм гыйбарәдән аңлашылганча, халыкның яшәеше, тормыш кыйбласы балаларга кушылган исемнәрдә ачык чагыла. Татар халкының үткәнен күзаллаганда, исемнәрнең кулланылу тарихына күз салу да җитә. Төрки-татарлар тормышында исламгача чор, ислам динен кабул итү, Октябрь инкыйлабына кадәрге һәм аннан соңгы дәвер, бүгенге яшәешебез балаларга кушылган исемнәрдә төгәл күренә.

Исемнең мәдәният символы булуы, катлаулы табигате борынгы чорларда ук аңа гаять зур игътибар барлыкка китерә. Борынгы дини-мифологик ышанулардан алып, соңрак дәверләрдә күренекле философлар, галимнәр хезмәтләрендә дә исемнең асылын, табигатен аңларга тырышу киң таралган. Бүгенге көнгә кадәр галимнәр кеше исеменең серен ачарга омтыла, аны лингвистик, психологик, фәлсәфи, тарихи, культурологик, физик яссылыкта тикшерәләр.

Татар исемнәр системасы белән кызыксыну, аларны махсус өйрәнү дә зур тарихка ия. Төрки исемнәрне туплаган беренче әһәмиятле чыганаклардан Мәхмүд Кашгари, Әбү Рәйхан әл-Бируни хезмәтләрен атарга мөмкин. Чыганак буларак, XIII–XIV гасырларда болгар, ә XV–XVIII гасырларда татар эпиграфик һәйкәлләрендә теркәлгән борынгы болгар һәм татар антропонимнары зур кыйммәткә ия. Татар антропонимиясенә караган кыйммәтле материаллар нәсел шәҗәрәләрендә сакланып калган. Татар шәҗәрәләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән М.И. Әхмәтҗанов үзенең хезмәтләрендә күп гасырлар дәвамында тупланып килгән фактик материалны фәнни әйләнешкә кертеп, татар антропонимикасы фәнендә XIII–XX гасырлар һәм хәзерге татар исемнәр системасының үсеш-үзгәреш тенденцияләрен күрсәтә.

Тарихи антропонимияне чагылдырган чыганаклардан XVI–XIX гасырларга караган «Ревизские сказки», Казан язу (писцовые) кенәгәләрен аерым атарга кирәк. Аларда шул чорларда яшәгән кешеләрнең исемнәренең русча язу барышында алдагы чорларга күчкән антропонимик вариантлары, исем бозылу үзенчәлекләре, беренче тапкыр фамилия куллану, аның төрләре ачык гәүдәләнә.

Күренекле тюркологлар В.В. Вельяминов-Зернов, С. Мельников, Н.И. Золотницкий, В.К. Магницкий, Н.И. Ашмарин һ. б. Идел Буе, Казан һәм Касыйм ханлыкларында яшәгән төрки-татарларның исемнәрен туплаган.

XIX–XX гасыр башында басылган махсус циркулярлар, календарь һәм исемлекләр, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров, Г. Тукай хезмәтләре дә татар исемнәренең составын, үзенчәлекләрен ачыклауда зур ярдәм булып тора.

XX гасырның 60 нчы елларыннан татар антропонимиясенә багышланган махсус монографик хезмәтләр күренә башлый. Бу беренче чиратта татар ономастика мәктәбенә нигез салучы күренекле галим Г.Ф. Саттаров эшчәнлеге белән турыдантуры бәйләнгән. Галимнең берничә дистә ел дәвамында уңышлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә тупланган материаллары

1981 елда «Татар исемнәре сүзлеге» буларак дөнья күрде. Татар исемнәренең төп базасын тәкъдим иткән бу күләме һәм эчтәлеге ягыннан беренче тулы аңлатмалы сүзлектә 10 меңгә якын (төрдәшләре белән 15 меңнән артык) кеше исеме һәм аларның этимологияләре бирелгән. Әйтергә кирәк, сүзлек башка төрки халыкларның кеше исемнәре сүзлеге төзелүгә дә җирлек, үрнәк вазифасын үтәде. Шулай ук байтак еллар дәвамында әлеге сүзлектә бирелгән исемнәрнең татарча язылышы орфографик норма буларак та кабул ителеп килде.

1998 елда Г.Ф. Саттаров «Татар исемнәре ни сөйли?» дип аталган хезмәтен бастырды. Биредә милли исемнәребез хәзинәсе мөмкин кадәр бай, тулы булсын дигән максатны күздә тотып, төрле чыганаклардан җыйналган 15 меңгә якын (төрдәшләре белән 20 меңнән артык) татар ир-ат һәм хатын-кыз исеме туплап бирелгән. Аларның татарча һәм русча дөрес язылышлары, генезислары күрсәтелгән, лексик мәгънәләре һәм этимологияләре аңлатылган. Әлеге хезмәт өч бүлектән тора. Беренче бүлектә теоретик материал яктыртылса, икенче бүлектә сүзлек бирелгән, өченче бүлектә исә, бала туугa һәм исем кушуга бәйле гореф-гадәт һәм йолалар тулысынча чагылыш тапсын өчен, төрле авторларның язмалары тәкъдим ителә, татарларда кешегә эндәшүмөрәҗәгать сүзләре бирелгән. 2019 елда Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре: аңлатмалы сүзлек» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 551 б.) басылып чыга. Әлеге хезмәт Казан төрки-татар ономастика мәктәбенең төп казанышларыннан саналырга хаклы.

Татар исемнәре сүзлек-белешмәлеген төзү омтылышлары соңрак Г.Ф. Саттаров шәкертләре тарафыннан да ясалды. Мисал өчен, 2000 елда Г.Р. Галиуллинаның «Личные имена татар в XX веке» (Казан: Матбугат йорты) монографик хезмәтендә XX гасырда татарлар арасында популяр исемнәрнең рус телендә аңлатмалы белешмәлеге тәкъдим ителә.

Татар кеше исемнәре сүзлегенә бәйле тагын бер хезмәтне – 2005 елда дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н дә атау кирәк. Биредә татар халкында актив булган кайбер кеше исемнәре һәм аларның мәгънәләре (чыганак телне дә күрсәтеп) кушымта буларак (832–847 битләр) бирелгән.

Узган гасыр урталарында төрки-татар кеше исемнәренең татарча-русча дөрес язылышын сүзлек итеп бастыру мәсьәләсе күтәрелә. 1965 елда РСФСР Министрлар советы таләбе нигезендә Мәскәүдә «Справочник личных имен народов РСФСР» (Москва: Советская энциклопедия, 1965, 253 с.) сүзлеге дөнья күрә. Күренекле галимнәр Н.А. Баскаков, Е.А. Бокарёв, Н.А. Белык, С.И. Ожегов һәм А.В. Суперанская редакторлыгында эшләнгән әлеге сүзлектә 17 милләтнең киң таралган кеше исемнәре белән бергә, аерым бүлек буларак, 400 чамасы татар исеме да кертелә. Татарларда актив кеше исемнәре бу сүзлектә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре дигән ике өлешкә бүлеп бирелә, аларның татарча гына түгел, русча да дөрес язылышы күрсәтелә. 1979 елда бу сүзлекнең икенче басмасы, 1987 елда өченче басмасы чыгарыла. 1989 елда А.В. Суперанская редакторлыгында «Справочник личных имен народов РСФСР» (Москва: Русский язык, 1989, 656 с.) сүзлегенең дүртенче басмасы нәшер ителә. Биредә инде 36 милләтнең, шул исәптән татар халкының да киң кулланылышка ия кеше исемнәре кертелә.

1973 елда Татарстан АССР Министрлар советының ЗАГС бүлеге соравы нигезендә Г.С. Сабирҗанов редакторлыгында «Справочник татарских личных имен» (Казань: Татар. кн. изд-во, 1973, 99 с.) дөнья күрә. И.В. Большаков һәм Р.Х. Субаевалар тарафыннан төзелгән әлеге 99 битлек сүзлек-белешмәдә татар телендә иң актив кулланылган кеше исемнәре һәм отчестволарының да татарча һәм русча дөрес язылышы бирелә.

1989 елда Татарстан китап нәшриятында Г.Ф. Саттаровның «Исемең матур, кемнәр куйган?» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 255 б.) исеме астында чираттагы китабы басыла. Хезмәтнең бер өлеше буларак, татарча һәм русча язылышлары чагылдырылган татар исемнәре тупламы тәкъдим ителә. Автор башта ир-ат исемнәрен, алардан ясалган отчество һәм фамилияләрнең кайбер кыен очракларын күрсәтеп, аннан соң алфавит тәртибендә хатын-кыз исемнәрен урнашты-

ра. Галим билгеләвенчә, әлеге туплам тулылыкка дәгъва итми.

Татар кеше исемнәренең шактый төгәл һәм тулы орфографик сүзлеге 2006 елда «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» исеме астында дөнья күрә. Әлеге сүзлекнең авторлары – Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С. Сабирҗанов, К.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллина. Сүзлек паспорт һәм ЗАГС идарәләре хезмәткәрләренә, төрле дәүләт оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына татар кеше исемнәре һәм фамилияләренең орфографиясе буенча кулланма буларак тәкъдим ителә.

2022 елда Татарстан Республикасы ЗАГС идарәсе заказы нигезендә татар кеше исемнәре, отчество, фамилияләрнең русча-татарча орфографик белешмәлеге эшләнә. Бүгенге көндә әлеге белешмәлек татар исемнәре орфографиясеннән төп күрсәтмә материал санала.

Татар исемнәрен туплау, сүзлекләрен төзү тарихы шактый бай булуга карамастан, бүгенге көндә яңа сүзлек булдыру ихтыяҗы гаять зур, чөнки җәмгыять үсешенә тыгыз бәйле бу берәмлекләрнең составы тиз үзгәрүчән. Телебездә яңа төр исемнәр даими туып тора, яки традицион саналган исемнәр, яңа яңгыраш алып, тиз арада мөстәкыйль исем булып формалашып җитә. Шулай ук татар теленең кеше исемнәре системасы ачык булу сәбәпле, башка телләрдән дә чит тел берәмлекләре бик җиңел үтеп керә. Гамәлдә йөргән сүзлекләрдә объектив сәбәпләр аркасында алар урын алмаганлыктан, халык арасында мәгънәләрен төрлечә аңлату яки бары тик яңгырашына гына карап исем кушу очраклары шактый.

Бүгенге татар гаиләләренең зур күпчелегендә яңа туган балага исем сайлауга җитди якын килеп, милли исемнәребезне кушу традициясе сакланып килә, алай гына да түгел, борынгы исемнәребезгә карата тирән кызыксыну арта. Шулай да еш кына бу йоланың мөһимлеген тулаем күзалламыйча яки исемнәрнең мәгънәләренә төшенмәү сәбәпле, очраклы, мәгънәсез исемнәр кушу, заманча дип санап, эчтәлеге бөтенләй булмаган исемнәр уйлап чыгару тенденциясе дә күзәтелә. Әлеге үзенчәлек соңгы елларда аеруча киң таралыш ала башлады. Шуңа бәйле гасырлар дәвамында милли исемлегебез үзгәрендә торган, инде соңгы берничә дистә ел татарлар арасында кулланыла башлаган исемнәрне туплаган, аларның мәгънәләре аңлатылган сүзлек кирәклеге көн үзәгенә басты.

Туган телебездә аралашу мөмкинлеге чикле милләттәшләребезгә, аерым халыкларның антропонимик системаларын өйрәнүче галимнәргә, татар исемлеге белән кызыксынучы башка катлам вәкилләренә дә әһәмиятле булуын истә тотып, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Казан федераль университеты галимнәре катнашында «Татар исемнәренең татарча-русча аңлатмалы сүзлеге»н әзерләде.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән әлеге сүзлек үткән дәверләрдән кулланылып килгән исемнәрне һәм бүгенге көндә исемлегебезгә килеп кергән берәмлекләрне туплап бирә.

Хезмәтнең югарыда билгеләп үтелгән сүзлек, белешмәлекләрдән аермалы яклары, яңалыгы буларак түбәндәгеләрне билгеләү зарур.

Сүзлектә беренче тапкыр исем турында мәгълүмат татар һәм рус телләрендә китерелә.

XX гасыр ахыры – XXI гасырның бүгенге көненә кадәр кулланылган исемнәр тоташ сайлау алымы белән ЗАГС метрик исемлекләреннән алынды.

Сүзлектә татар алфавиты нигезендә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре аерым бирелә, аннан соң килеп чыгышы, мәгънәсе татар һәм рус телендә аңлатыла.

Элегрәк чыккан сүзлекләрдә урын алган исемнәрнең мәгънәләре башка телләрнең сүзлекләрен, тарихи, мәдәни, лингвистик чыганакларны өйрәнү нәтиҗәсендә төгәлләштерелә, лингвомәдәни мәгълүмат белән тулылындырыла.

Мәкаләләрдә баш исем орфографик норма итеп бирелә. Диалекталь вариантлар, сөйләм теле формаларының исем буларак китерелгәннәре (мәсәлән, *Гөлкәй, Гүзәлем, Хәмәтнур* һ. б.), фонетик вариантларның киң таралганнары гына баш исем астында бирелеп, башка вариантлар төрдәшләр (вариантлар) буларак күрсәтелде.

Кеше исемнәренең килеп чыгышы, чыганак һәм арадаш телләр мөмкин кадәр тәгаенләнә.

Сүзлек Казан төрки-татар ономастика мәктәбенең традицияләренә нигезләнеп төзелә, Г.Ф. Саттаров сүзлекләрендә тәкъдим ителгән терминнар, атамалар мөмкин кадәр саклады, мисал өчен, *борынгы төрки-татар, төрки-татар* терминнары шундыйлардан. Чыганаклары бу шәкелдә китерелгән исемнәрнең апеллятив нигезләре борынгы төрки телдә яки соңрак кулланылып, башка төрки телләрнең лексик системасында да саклануына карамастан, алар татар халкы арасында күп гасырлар дәвамында ялгызлык исеме буларак файдаланылалар һәм яңа исемнәр ясауда өлге, нигез вазифасын үтиләр.

Лингвистик яктан объективлыкны саклау максаты белән, исемнәрнең генезисы буларак беренче чыганак күрсәтелә, мәсәлән, **Айзирәк** (*бор. төрки – фар.*); **Бикәбану** (*бор. төрки – фар.*), **Сылугөл** (*бор. төрки – фар.*) һ. б. Әмма шуны искәртү зарур: мондый кушма исемнәрнең беренче компоненты борынгы төрки чыгышлы булсалар да, әлеге исемнәр татар теле җирлегендә барлыкка килгәннәр, татарлар тарафыннан балага кушылганнар һәм ***татар исемнәр*****е** саналалар.

Исем вариантларының аңлатмасы норматив исемгә юнәлдерелде, мәсәлән, **Эмир** *к.* Әмир; **Эльдар** *к.* Илдар һ. б.

Исемнәр системасында кулланыла торган бер төркем антропонимнарның ясалма икәнен дә искәртәсебез килә (*Зөлнара, Райнар, Рамвал, Рудэль, Эльзана* һ. б.) Мондый берәмлекләрнең мәгънәләре юк, аларның күбесе традицион исемнәргә аваздаш буларак кына ясала. Андый исемнәр *ясалма исем* тамгасы белән күрсәтелә.

Кеше исемнәренең ясалышы, язылышы, кулланылышы, бирелү мотивлары бик күп субъектив факторларга бәйле. Тегe яки бу исемнең килеп чыгышы, мәгънәсе хакында ачык чыганакларда, халык арасында, галимнәрнең хезмәтләрендә төрлечә чагылдырыла. Без исә күптөрле чыганаклар, милли менталитет һәм күзаллауларны, мәдәни, рухи традицияләребезне анализлап, татарлар арасында кулланылырга мөмкин булган исем кушу мотивларын, актуаль булырлык мәгънәләрне барлап, аңлатмаларны шәрехләдек.

Исемнәр системасының формалашуы һәм билгеле бер юнәлештә үсеш кичерүе үзеннән-үзе бармый. Аның нигезе гаиләдә салына, гаиләдә яңа туган балага сайланган исем үз чиратында бөтен исемнәр системасында тегe яки бу исемнең популярлашуына, я булмаса югалуына китерергә мөмкин.

Яңа туган бала гаиләгә бәхет, нур, өметләр алып килә. Исем кушу – балага иң изге хисләребезне, аның киләчәктә нинди шәхес булуына бәйле теләкләрне җиткерүнең бер юлы. Шул ук вакытта ул ата-анадан зур җаваплылык та таләп итә, чөнки яңа туган балага исем сайлау милли традицияләрнең саклануы, аларның дәвамчанлык күрсәткече дә булып тора. Баланы милли даирәгә алып керүдә беренче баскыч булып аңа милли исем кушу тора. Һәр ата-ана баласының бәхетле, сәламәт, акыллы, уңган булуын тели. Милли исемнәребезнең асылына нәкъ менә шушы сыйфатлар салынган да инде. Балаларыбызга исем кушканда тирән мәгънәле, матур яңгырашлы, рухыбызга туры килгән исемнәрне сайлау мөһим. Әлеге сүзлекнең төп максаты – бу юнәлештә кирәкле чыганак вазифасын үтәү.

*Гөлшат Галиуллина*